**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**Исполнительный комитет**
**Коморгузинского**
**сельского поселения**
**Атнинского муниципального района**
422758, с.Коморгузя, ул. Татарстана,
зд.40Б
Тел./факс.: (8-84369) 32022

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Әтнә муниципаль районы**
**Комыргуҗа авыл җирлеге**
**башкарма комитеты**
422758, Комыргуҗа авылы,
Татарстан урамы., 40 Б нчы йорт
Тел./факс.: (8-84369) 32022

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«30» сентябрь 2024 ел. № 9

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенең 28.02.2017 ел № 5 карары белән расланган “Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар план-графигын формалаштыру, раслау һәм алып бару тәртибе”нә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында**

"Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында" 2013 елның 05 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон, «Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 01.04.2020 N 98-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 01.05.2019 № 71-ФЗ Федераль закон, Татарстан Республикасы Әтнә районы прокуратурасының 2024 елның 28 июнендәге «02-08-02-2024/Прдп278-24» протесты нигезендә, Әтнә муниципаль районының Комыргуҗа авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Комыргуҗа авыл җирлеге җитәкчесенең 2017 елның 28 февралендәге 5 номерлы карары (21.07.2021, № 11, 03.04.2023 №6 редакциясендә) белән расланган Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының Комыргуҗа авыл җирлеге ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар план-графигын формалаштыру, раслау һәм алып бару тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. Тәртипнең 10 пунктын төшереп калдырырга;

1.2. 13 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

“13. План-графикка түбәндәгеләр керә:

1) дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында" 2013 елның 05 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законның 23 статьясы нигезендә билгеләнгән сатып алуларның идентификация кодлары;

2) объектның исеме һәм (яисә) сатып алу объектларының атамалары;

3) сатып алуларны гамәлгә ашыру өчен финанс белән тәэмин итү күләме;

4) планлаштырыла торган сатып алуларны гамәлгә ашыруның сроклары (вакыты);

5) «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 05 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законның 20 статьясы нигезендә товарны, эшне яисә хезмәтләрне сатып алулар турында иҗтимагый фикер алышу турында мәгълүмат;

6) "Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында" 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьяның 3 өлешендәге 2 пунктында каралган тәртип белән билгеләнгән башка мәгълүмат."

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында http://atnya.tatarstan.ru. адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җавапчылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Әтнә муниципаль районы
Комыргуҗа авыл җирлеге башлыгы

Гатауллин Ф.Т.